**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 13 декабрендәге 5160 номерлы карары**

# Казан шәһәренең инженерлык сагы гидротехник корылмаларына комплекслы тикшерү уздыру өлешендә Казан шәһәренең гидротехник корылмаларын эксплуатацияләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатыннан оешмаларга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, 2002 елның 14 ноябрендәге 161-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы «Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товар җитештерүче, эшләр башкаручы, хезмәтләр күрсәтүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм күрсәтелгән субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендәге грантлар алучыларны сайлап алуны уздыруны җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәренең инженерлык сагы гидротехник корылмаларына комплекслы тикшерү уздыру өлешендә Казан шәһәренең гидротехник корылмаларын эксплуатацияләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатыннан оешмаларга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен әлеге карарга 1 номерлы кушымта нигезендә расларга.

2. Субсидия Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы «Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товар җитештерүче, эшләр башкаручы, хезмәтләр күрсәтүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм

күрсәтелгән субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендәге грантлар алучыларны сайлап алуны уздыруны җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында»гы карарының 18 пункты нигезендә милекне карап тоту һәм аннан максатчан файдалануны тәэмин итү белән турыдан-туры бәйле чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итүгә бирелә дип билгеләргә.

3. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү буенча вәкаләтле орган итеп Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитетын билгеләргә.

4. Казан шәһәренең инженерлык сагы гидротехник корылмаларына комплекслы тикшерү уздыру өлешендә Казан шәһәренең гидротехник корылмаларын эксплуатацияләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатыннан оешмаларга субсидияләр бирү комиссиясе турында нигезләмәне әлеге карарга 2 номерлы кушымта нигезендә расларга.

5. Казан шәһәренең инженерлык сагы гидротехник корылмаларына комплекслы тикшерү уздыру өлешендә Казан шәһәренең гидротехник корылмаларын эксплуатацияләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатыннан оешмаларга субсидияләр бирү комиссиясе составын әлеге карарга 3 номерлы кушымта нигезендә расларга.

6. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 13 декабрендәге
5160 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең инженерлык сагы гидротехник корылмаларына комплекслы тикшерү уздыру өлешендә Казан шәһәренең гидротехник корылмаларын эксплуатацияләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатыннан оешмаларга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Казан шәһәренең инженерлык сагы гидротехник корылмаларына комплекслы тикшерү уздыру өлешендә Казан шәһәренең гидротехник корылмаларын эксплуатацияләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатыннан оешмаларга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү процедурасын билгели.

2. Субсидия бирү максаты – Казан шәһәренең инженерлык сагы гидротехник корылмаларына комплекслы тикшерү уздыру өлешендә Казан шәһәренең гидротехник корылмаларын эксплуатацияләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү.

3. Субсидияләр Казан шәһәре Башкарма комитетының вәкаләтле органы (алга таба – Вәкаләтле орган) өчен каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә агымдагы финанс елына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының җыелма бюджет исемлегендә бюджет чыгымнары классификациясенең тиешле кодлары буенча әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга бирелә.

4. Тиешле финанс елына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында каралган субсидияләр Вәкаләтле органның Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы карамагындагы Казначылык департаментының Казан шәһәре территориаль бүлекчәсендә ачылган шәхси счетында исәпкә алына.

5. Субсидия алучылар сайлап алуда катнашу өчен оешмалар (алга таба – гаризалар, сайлап алуда катнашучылар) юллаган тәкъдимнәрне (гаризаларны)

соратып алу юлы белән уздырыла торган сайлап алу нәтиҗәләре буенча, сайлап алуда катнашучыларның сайлап алу категорияләренә, критерийларына туры килүенә һәм гаризаларның керү чиратына карап, Казан шәһәренең инженерлык сагы гидротехник корылмаларына комплекслы тикшерү уздыру өлешендә Казан шәһәренең гидротехник корылмаларын эксплуатацияләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатыннан оешмаларга субсидияләр бирү комиссиясе (алга таба – комиссия) тарафыннан билгеләнә.

6. Субсидия хакында мәгълүматлар, бюджет турында закон (карар) (бюджет турындагы законга (карарга) үзгәрешләр кертү хакында закон (карар)) кабул ителгән көннән соң килә торган унбиш эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (бердәм портал бүлегендә) урнаштырыла.

Субсидия алуга гаризалар кабул итү турында мәгълүмат Вәкаләтле орган тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми сайтында (https://kzn.ru/meriya/ispolnitelnyy-komitet/komitet-zhilishchno-kommunalnogo-khozyaystva/dokumenty/) (алга таба – рәсми сайт) урнаштырыла.

7. Субсидия алучыларны сайлап алуны уздыру турында белдерү сайлап алу башланырга кимендә бер календарь көн кала бердәм порталда, шулай ук рәсми сайтта урнаштырыла. Анда түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелә:

- сайлап алуны уздыру вакыты (сайлап алуда катнашучылар тарафыннан гаризалар бирүнең (кабул итүнең) башлану (тәмамлану) көне һәм вакыты), ул сайлап алуны уздыру турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган биш календарь көннән ким була алмый;

- Вәкаләтле органның атамасы, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы;

- «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны уздыру тәэмин ителә торган сайтның домен исеме һәм (яки) челтәр адресы, һәм (яки) сәхифәләре;

- сайлап алуда катнашучыларга карата әлеге Тәртипнең 9 пункты нигезендә куелган таләпләр һәм сайлап алуда катнашучыларның күрсәтелгән таләпләргә туры килүләрен раслау өчен алар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге;

- әлеге Тәртипнең 8 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучылар җавап бирергә тиешле сайлап алу критерийлары;

- сайлап алуда катнашучылар тарафыннан гаризалар тапшыру тәртибе

һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан әлеге Тәртипнең 12, 13 пунктлары нигезендә тапшырыла торган гаризалар формасына һәм эчтәлегенә карата таләпләр;

- гаризаларны кире алу тәртибе, гаризаларны кире кайтару, шул исәптән гаризаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгеләү тәртибе, гаризаларга үзгәрешләр кертү тәртибе;

- гаризаларны әлеге Тәртипнең 15-18 пунктлары нигезендә карап тикшерү кагыйдәләре;

- гаризаларны кире кагу тәртибе, шулай ук аларны кире кагу нигезләре турындагы мәгълүмат;

- әлеге Тәртипнең 14 пункты нигезендә гаризаларны эшләп бетерү өчен кире кайтару тәртибе;

- сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны уздыру турындагы белдерү нигезләмәләре буенча аңлатмалар бирү тәртибе, аңлатмалар бирүнең башлану һәм тәмамлану көне;

- сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) субсидия бирү турындагы килешүне (алга таба – килешү) имзаларга тиешле вакыт аралыгы;

- җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартлары;

- әлеге Тәртипнең 23 пункты белән билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе;

- сайлап алу беркетмәсен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге бердәм порталда һәм рәсми сайтта урнаштыру көне. Ул сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмаска тиеш.

8. Сайлап алу критерийлары:

- хуҗалык алып бару өчен Казан шәһәренең гидротехник корылмаларын тапшыруны раслый торган документлар булу;

- Казан шәһәренең әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән гидротехник корылмаларын эксплуатацияләү белән бәйле эшләрне гамәлгә ашыру.

9. Сайлап алуда катнашучы гариза бирү көненә кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган датага түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

- Казан шәһәре милкендә булган, хуҗалык алып бару хокукында тапшырылган гидротехник корылмага ия;

- чит ил, шул исәптән Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга

таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган очракта) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендә оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашуы белән гамәлгә ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

- экстремистик эшчәнлеккә яки терроризмга катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

- БМО Уставының VII бүлеге белән каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары нигезендә махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар яисә массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

- субсидияләр бирү максатларына туры килә торган максатлар өчен башка хокукый актлар нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан акчалар алмый;

- «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында»гы федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

- бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы юк яки бурычның күләме Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункт белән билгеләнгән күләмнән артмый;

- Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча түләү вакыты узган бурычы һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына түләү вакыты узган башка бурычы юк;

10. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидия рәвешендә алынган акчалар максатчан характерда була һәм оешма тарафыннан

башка максатларда файдаланыла алмый.

11. Субсидия әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән хезмәтләр өчен түләүгә тотыла.

12. Субсидия алуга сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучы Вәкаләтле органга түбәндәге документларны тапшыра:

- әлеге Тәртипкә 1 номерлы кушымтада китерелгән форма буенча тутырылган, җитәкче яки башка вәкаләтле зат тарафыннан имзаланган гариза;

- җитәкче (вәкаләтле зат) вәкаләтләрен раслый торган документлар күчермәләре;

- хуҗалык алып бару өчен Казан шәһәренең гидротехник корылмаларын тапшыруны раслый торган документлар;

- сайлап алуда катнашучының бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы юклыгын яки бурычның күләме Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункт белән билгеләнгән күләмнән артмавын раслый торган документлар күчермәләре;

- әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән, субсидия акчалары хисабына башкару планлаштырыла торган чараларны гамәлгә ашыруга расланган сметаларны һәм исәпләүләрне теркәп, субсидия күләмен исәпләү;

- субсидия күчерелә торган исәп-хисап счеты турында мәгълүмат.

Тапшырылган документларның күчермәләре таныкланырга һәм аларга мөһер сугылган (булган очракта) булырга тиеш.

Оешма тапшырылган гаризадагы һәм документлардагы мәгълүматның дөреслеге өчен җаваплы.

Сайлап алуда катнашучы документларны Вәкаләтле органга кәгазь чыганакта һәм кулдан тапшыра.

13. Оешма Вәкаләтле орган адресына бер генә гариза, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә оешма турында мәгълүмат бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалык, шулай ук шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (физик зат өчен) юллый ала.

14. Гариза эшләп бетерү өчен Комиссия тарафыннан дәгъвачыга гаризаларны карап тикшерү вакыты тәмамланганчыга кадәр өченче эш көненнән дә соңга калмыйча кайтарыла.

Гаризаны эшләп бетерүгә җибәргәндә, аны кире кайтару сәбәпләре күрсәтелә. Катнашучы гаризаны эшләп бетерергә юллаган көннән соң килә торган көн эчендә гаризага үзгәрешләр кертергә һәм аны кабат бирергә хокуклы.

Өстәмә эшләп җибәрелгән гариза яңадан теркәлми һәм дәгъвачының беренчел гаризасы имзаланган көн гариза бирү датасы булып санала.

Документларда бозып төзәтелгән урыннар, өстәмә язулар булган очракта, шулай ук Тәртипнең 12 пунктына туры килмәсә, гаризалар эшләп бетерүгә җибәрелә.

15. Сайлап алуда катнашуга гаризалар кабул итү тәмамланганчы, сайлап алуда катнашучы сайлап алуда катнашу турындагы гаризага үзгәрешләр кертергә хокуклы. Ул сайлап алуда катнашуга яңа редакциядә гариза бирү юлы белән гамәлгә ашырыла. Сайлап алуда катнашучы тарафыннан Вәкаләтле органга элек җибәрелгән сайлап алуда катнашу өчен гариза карап тикшерелми. Сайлап алуда катнашуга яңа редакциядә бирелгән гариза яңадан теркәлми, һәм сайлап алуда катнашучы тарафыннан беренчел гариза бирелгән көн гариза бирү датасы булып санала.

16. Комиссия утырышы көненә кадәр сайлап алуда катнашучы сайлап алуда катнашуга гаризаны почта аша заказлы хат белән җибәрелгән яки кулга тапшырылган язмача гариза нигезендә кире алырга хокуклы. Бу очракта гариза Комиссия утырышында карап тикшерелми. Әлеге хәбәрнамәне Вәкаләтле орган тарафыннан теркәү датасы гаризаны кире алу көне булып тора.

17. Вәкаләтле орган, кабул итү датасын, вакытын күрсәтеп, гаризаны кергән көнне терки.

18. Комиссия гаризалар кабул итү тәмамланган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә:

- сайлап алуда катнашучыларга карата түбәндәге документларны һәм мәгълүматны соратып алуга тиешле мөрәҗәгатьләр җибәрү юлы белән сайлап алуда катнашучылар тарафыннан тапшырылган документларны, шул исәптән аларның әлеге Тәртипнең 9 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен карап тикшерә:

1) Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан яки Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Федераль салым хезмәтенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге https://nalog.ru рәсми сайтыннан бастырып алына);

2) гаризалар кабул итү тәмамланган көнгә сайлап алуда катнашучының Тәртиптә күрсәтелгән чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатыннан Казан шәһәренең башка норматив хокукый актлары нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан акчалар алуы (алмавы) турында мәгълүмат;

3) экстремистик эшчәнлеккә яки терроризмга катнашы барлыгы турында

белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә сайлап алуда катнашучы турында белешмәләр булу (булмау) хакында мәгълүмат (Финанс мониторингы буенча федераль хезмәтнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге www.fedsfm.ru рәсми сайтының тиешле бүлегеннән бастырып алына);

4) «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында»гы федераль закон нигезендә чит ил агентлары реестрында сайлап алуда катнашучы турында белешмәләр булу (булмау) турында мәгълүмат (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге www.minjust.gov.ru рәсми сайтыннан бастырып алына);

5) БМО Уставының VII бүлеге белән каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары нигезендә махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар яисә массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә сайлап алуда катнашучы турында белешмәләр булу (булмау) хакында мәгълүмат (Финанс мониторингы буенча федераль хезмәтнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге www.fedsfm.ru рәсми сайтының тиешле бүлегеннән бастырып алына);

- сайлап алу җиңүчеләрен билгеләү турында яки гаризаларны кире кагу турында карар кабул итә. Сайлап алу җиңүчеләрен билгеләү турындагы карар әлеге Тәртипкә 2 номерлы кушымта нигезендә сайлап алуга йомгак ясау беркетмәсе рәвешендә рәсмиләштерелә.

Субсидия бирү, субсидия алу өчен сайлап алуда катнашуга гариза тапшырган көнне һәм вакытны исәпкә алып, чират тәртибендә гамәлгә ашырыла.

Гаризалар кабул итү вакыты тәмамланганнан соң Вәкаләтле органга кергән гариза теркәлми.

Гаризаларны сайлап алуда катнашучының язма гаризасы нигезендә кире алудан тыш, сайлап алуда катнашучылар тарафыннан тапшырылган гаризалар һәм аларга теркәп бирелгән документлар кире кайтарылмый.

Гаризалар бирү өчен каралган вакыт эчендә бер генә гариза да тапшырылмаган очракта, сайлап алу узмаган дип танyла. Сайлап алуны узмаган дип тану турындагы мәгълүмат, гаризалар бирү вакыты тәмамланган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча, рәсми порталда урнаштырыла.

19. Гаризаны кире кагу өчен нигезләр:

- хокукый акт белән каралган, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

- конкурста катнашучы тарафыннан тапшырылган гаризаларның һәм (яки) документларның хокукый акт белән каралган, сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

- хокукый акт белән билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслау максатыннан сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

- сайлап алуда катнашучының гаризалар бирү өчен билгеләнгән көннән һәм (яки) вакыттан соң гариза тапшыруы;

- сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртиптә күрсәтелгән критерийларга һәм таләпләргә туры килмәве;

- әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга субсидияләр бирү өчен бюджет акчаларын алучы буларак Вәкаләтле органга билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән агымдагы финанс елына бюджет йөкләмәләре лимитлары бетү.

20. Комиссия, сайлап алуда җиңүчеләрне билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, рәсми порталда сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыра. Ул түбәндәге белешмәләрне үз эченә ала: гаризаларны карап тикшерүне уздыру көне, вакыты һәм урыны; гаризалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат; гаризаларны кире кагу сәбәпләрен, шул исәптән мондый гаризаларның сайлап алу уздыру турындагы белдерүнең кайсы нигезләмәләренә туры килмәвен күрсәтеп, гаризалары кире кагылган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат; сайлап алуда җиңүчеләрнең атамалары һәм аларга бирелә торган субсидия күләме.

21. Вәкаләтле орган:

- сайлап алуга йомгак ясаган көннән алып биш эш көне эчендә сайлап алуда җиңүчегә гаризада күрсәтелгән электрон почта аша субсидия бирү турында килешү проектын юллый;

- сайлап алуда җиңүчедән имзаланган килешүне алганнан соң өч эш көне эчендә сайлап алуда җиңүчегә әлеге Тәртипкә 3 номерлы кушымтада китерелгән бәяләмә формасында субсидия бирү мөмкинлеге турында карар кабул итә;

- субсидия бирү мөмкинлеге турында бәяләмәне имзалаганнан соң өч эш көне эчендә субсидия алучы белән субсидия бирү турында килешүне имзалый.

Килешү Казан шәһәре Башкарма комитеты Финанс идарәсенең 2023 елның 12 гыйнварындагы 8 номерлы әмере белән расланган типлаштырылган форма буенча төзелә.

22. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

- субсидия бирүнең күләме, максаты, шартлары һәм тәртибе;

- субсидия күчерү вакыты;

- әлеге Тәртип белән билгеләнгән шартлар бозылган очракта, килешүне (шартнамәне) өзү тәртибе;

- бюджет акчаларын алучы буларак төп бүлүчегә килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкинлеге булмауга китерә торган итеп бюджет йөкләмәләренең элек җиткерелгән лимитлары киметелгән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү яки, яңа шартлар буенча килештерүгә ирешелмәгәндә, килешүне өзү тәртибе;

- субсидияләр бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап бирү тәртибе, вакыты һәм формасы;

- читтән кертелгән югары технологияле җиһазлар, чимал һәм комплектлаучы эшләнмәләр сатып алганда (алар белән тәэмин иткәндә) Россия Федерациясе валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән, шулай ук әлеге акчаларны бирү нәтиҗәләренә ирешү белән бәйле хокукый актларда билгеләнгән бүтән операцияләрдән тыш, субсидия алучы юридик затлар, шулай ук субсидия алучылар белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы башка юридик затлар тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан алынган акчалар хисабына чит ил валютасы сатып алуны тыю;

- субсидияләр алучылар өчен Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап яисә корреспондент счетларына субсидияләр күчерү;

- субсидия алучының субсидия бирүче Вәкаләтле орган тарафыннан аңа карата субсидия бирү тәртибе һәм шартлары үтәлешен, шул исәптән аны бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәлешен тикшерүне, шулай ук дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары тарафыннан субсидия алучының Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыруга һәм мондый нигезләмәләрне килешүгә кертүгә ризалыгы.

Кирәк булган очракта, Вәкаләтле орган субсидия алучылар белән килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

23. Килешүне алганнан соң өч эш көне эчендә Вәкаләтле органга субсидия алучы исеменнән эш йөртү хокукына ия зат тарафыннан имзаланган килешү проектын тапшырмаган очракта, субсидия алучы килешү төзүдән баш тарткан дип таныла.

24. Вәкаләтле орган субсидия бирү турында килешү төзелгән көннән алып ун эш көне эчендә субсидия алучылар өчен Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетларына үзенең шәхси счетыннан акча күчерә.

Субсидия күләме әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатка ярашлы рәвештә субсидия алучы чыгымнарын финанс белән тәэмин итүнең 100 процентын тәшкил итә.

25. Субсидия бирүне кире кагу турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

- субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документлар әлеге Тәртип белән билгеләнгән таләпләргә туры килми яки күрсәтелгән документлар (әлеге Тәртипнең 12 пункты) тапшырылмаган (тулы күләмдә тапшырылмаган);

- субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүмат дөрес түгел;

- оешма әлеге Тәртип белән билгеләнгән критерийларга туры килми;

- Казан шәһәре Думасының субсидия түләүгә бюджет турындагы карары белән билгеләнгән акчалар әлеге Тәртип нигезендә субсидия сыйфатында инде бирелгән.

26. Казан шәһәренең инженерлык сагы гидротехник корылмаларына комплекслы тикшерү уздыру өлешендә Казан шәһәренең гидротехник корылмаларын эксплуатацияләүгә бәйле рәвештә барлыкка килгән чыгымнар субсидияләүнең тиешле күләмен билгели торган исәпләүләр белән раслана.

Субсидия күләме – Казан шәһәренең инженерлык сагы гидротехник корылмаларын комплекслы тикшерү белән бәйле чыгымнар.

27. Субсидия алучы квартал саен хисап аеннан соң килә торган айның бишенче числосына кадәр Вәкаләтле органга Казан шәһәренең инженерлык сагы гидротехник корылмаларына комплекслы тикшерү уздыру өлешендә Казан шәһәренең гидротехник корылмаларын эксплуатацияләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен бүлеп бирелгән акчалардан файдалану хакында субсидия бирү турындагы килешү белән билгеләнгән форма буенча хисап тапшыра.

28. Субсидия бирү нәтиҗәсе – Казан шәһәренең инженерлык сагы гидротехник корылмаларының торышы турында хисап. Ул материаллар җыю һәм аларны анализлау, визуаль тикшерү, геофизик тикшеренүләр үткәрү

нәтиҗәләрен үз эченә ала.

29. Субсидия алучы хисап елыннан соң килә торган елның 1 декабренә кадәр Вәкаләтле органга, түбәндәге раслаучы документларны теркәп, субсидия бирү турындагы килешү белән билгеләнгән форма буенча субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү хакында хисап тапшыра:

- техник бирем;
- хезмәтләр күрсәтүгә шартнамә;
- чаралар үткәрүгә смета;
- башкарылган эшләр/күрсәтелгән хезмәтләр турында акт, накладнойлар;
- түләү йөкләмәләре;
- объектны комплекслы тикшерү программасы;
- дефект ведомостен да кертеп, алынган башлангыч мәгълүматларны анализлау, объектны тикшерү нәтиҗәләре;
- тикшерелә торган объектның гидрометеорологик яктан өйрәнелүе турында мәгълүмат;
- башкарылган геофизик тикшеренүләр нәтиҗәләре;
- инженерлык тикшеренүләре программасы.

30. Әлеге Тәртипнең 29 пункты нигезендә хисап тапшырылганнан соң, Вәкаләтле орган 15 эш көне эчендә субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне тикшерә.

31. Субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылганда, шул исәптән әлеге шартларның бозылуы Вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органы үткәргән тикшерү фактлары буенча ачыкланган очракта, бирелгән субсидия Вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән башлап утыз эш көне эчендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты керемнә тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш.

32. Акчаларны Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты керемнә ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тарткан очракта, алар Вәкаләтле орган тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә утыз көн эчендә мәҗбүри рәвештә түләттерелергә тиеш.

33. Россия Федерациясе законнары нигезендә Вәкаләтле орган субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының, шул исәптән аларның субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәлешен тикшерә, шулай ук дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары тарафыннан субсидия алучыларга карата Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә тикшерү үткәрелә.

34. Вәкаләтле органга субсидияләр алучылар тарафыннан тапшырыла

торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык субсидияләр алучыларның тиешле вазифаи затларына һәм җитәкчеләренә йөкләнә.

35. Бюджет акчаларыннан файдалануны Вәкаләтле орган контрольдә тота.

---

Казан шәһәренең инженерлык сагы
гидротехник корылмаларына
комплекслы тикшерү уздыру өлешендә
Казан шәһәренең гидротехник
корылмаларын эксплуатацияләүгә бәйле
чыгымнарны финанс белән тәэмин итү
максатыннан оешмаларга Казан шәһәре
муниципаль берәмлеге бюджетыннан
субсидияләр бирү тәртибенә
1 номерлы кушымта
(Форма)

**Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан**
**субсидия алу өчен сайлап алуда катнашуга**
**гариза**

Субсидия атамасы_________________________________________

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Гариза бирүче (оешма атамасы) | |
| 2 | Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН) | |
| 3 | Төп дәүләт теркәве номеры (ОГРН) | |
| 4 | Юридик адрес | |
| 5 | Электрон почта адресы | |
| 6 | Телефон номеры | |
| 7 | Директор (фамилиясе, исеме, атасының исеме) | |
| 8 | Вәкаләтләрне раслый торган документ (атамасы, датасы, номеры) | |
| 9 | Субсидия күләме, сумнарда | |
| 10 | Хисап чоры | |
| 11 | Хезмәт күрсәтү урыны (адресы) | |
| 12 | Әлеге гариза белән сайлап алуга бәйле мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгымны белдерәм<br>______________<br>(имза) | |
| 13 | Субсидия алу өчен сайлап алуда катнашу мөмкинлеге бирә торган дөрес булмаган белешмәләр тапшырган өчен Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә җаваплылык каралган булуы турында әлеге гариза белән хәбәр ителде<br>_______________<br>(имза) | |

| | | |
|---|---|---|
| | | |
| 14 | Әлеге гариза белән түбәндәгеләрне раслыйм:<br>- салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар һәм процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурыч юк;<br>- Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча түләү вакыты узган бурыч һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына түләү вакыты узган башка бурыч юк<br><br>________________<br>(имза) | |
| 15 | Сайлап алуны уздыру шартлары белән таныштым һәм, тәртипкә нигезләнеп, түбәндәге исемлек буенча кирәкле документларны тапшырам | |
| 16 | Гаризага терким: | |
| | 1. | ___ биттә |
| | 2. | ___ биттә |
| | 3. | ___ биттә |
| | 4. | ___ биттә |

____________________________________________

(гариза бирүченең имзасы, вазифасы, фамилиясе һәм инициаллары)

Гариза бирү датасы: 20____елның «___»__________

Казан шәһәренең инженерлык сагы
гидротехник корылмаларына
комплекслы тикшерү уздыру өлешендә
Казан шәһәренең гидротехник
корылмаларын эксплуатацияләүгә бәйле
чыгымнарны финанс белән тәэмин итү
максатыннан оешмаларга Казан шәһәре
муниципаль берәмлеге бюджетыннан
субсидияләр бирү тәртибенә
2 номерлы кушымта
(Форма)

**______ номерлы сайлап алу**
**беркетмәсе**

____ елның «____» ___________ Казан шәһәре

1. Сайлап алуда катнашучыларның тәкъдимнәрен (гаризаларын) карап тикшерүне уздыру көне, вакыты һәм урыны:
______________________________________________________________________.

2. Карап тикшерүдә катнашучы комиссия әгъзалары:

| **Вазифаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме** | **Вазифасы** |
|---|---|
| | |

Карар кабул итү өчен кворум бар.

3. Сайлап алуда катнашучы түбәндәге затлардан тәкъдимнәр (гаризалар) алынды:

1)______________________________________________________________;

2)______________________________________________________________.

4. Тәкъдимнәре (гаризалары) кире кагылган сайлап алуда катнашучылар турында кире кагылу сәбәпләре, шул исәптән сайлап алу үткәрү турында игъланның мондый тәкъдимнәр (гаризалар) туры килми торган нигезләмәләре күрсәтелгән мәгълүмат:

| Сайлап алуда катнашучы атамасы | Тәкъдимне (гаризаны) кире кагу өчен нигезләр |
|---|---|
| | |
| | |

5. Субсидия бирү турында килешү төзелә торган субсидия алучының атамасы һәм аңа бирелә торган субсидия күләме:

_______________________________________________________________

Комиссия әгъзаларының имзалары:

Казан шәһәренең инженерлык сагы
гидротехник корылмаларына
комплекслы тикшерү уздыру өлешендә
Казан шәһәренең гидротехник
корылмаларын эксплуатацияләүгә бәйле
чыгымнарны финанс белән тәэмин итү
максатыннан оешмаларга Казан шәһәре
муниципаль берәмлеге бюджетыннан
субсидияләр бирү тәртибенә
3 номерлы кушымта
(Форма)

**Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидия бирү мөмкинлеге турында бәяләмә**

**Карап тикшерү предметы:**

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Сайлап алуда җиңүче | |
| 2 | Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН)/Исәпкә кую сәбәбе коды (КПП) | |
| 3 | Субсидия атамасы | |
| 4 | Субсидия күләме, сумнарда | |
| 5 | Хисап чоры | __.__.20__ – __.__.20__ |

**Эчтәлеге:**

________________________________________________________________
(субсидия бирүне җайга сала торган хокукый акт исеме)

________________________________________________________________
______________________________________________ (алга таба – Тәртип) буенча
________________________________________________________________
(сайлап алуда җиңүче атамасы)

оешма карары нигезендә ____________________________________ күрсәтелгән
(субсидия бирүне җайга сала торган хокукый акт пункты)

критерийларга туры килә һәм ____________________________________________
(субсидия бирүне җайга сала торган хокукый акт пункты)

күрсәтелгән имзаланган килешүне тапшырды.

Субсидиядән файдалану шартлары һәм максаты үтәлгән.

_______________________________________________________________________________

(бюджет акчаларын төп бүлүче атамасы)

субсидияне агымдагы финанс елына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының җыелма бюджет исемлегендә бюджет чыгымнары классификациясенең тиешле кодлары буенча каралган бюджет йөкләмәләре ассигнованиеләре һәм лимитлары чикләрендә бирә.

**Нәтиҗә:**

______________________________________________________________________________

(гариза бирүче атамасы)

______________________________________________________________________________

(субсидия бирүне җайга сала торган хокукый акт нигезендә субсидия бирү максатлары)

өчен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан әлеге максатларга ______________________________________________________________________________

(бюджет акчаларын төп бүлүче оешма атамасы)

тарафыннан каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә 20__ елның _________ алып 20__ елның _________ кадәр ___________ сум күләмендә субсидия бирергә.

______________________________________________________________/_________________/

(комиссия әгъзалары)

_________________

(дата)

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 13 декабрендәге
5160 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең инженерлык сагы гидротехник корылмаларына комплекслы тикшерү уздыру өлешендә Казан шәһәренең гидротехник корылмаларын эксплуатацияләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатыннан оешмаларга субсидияләр бирү комиссиясе турында нигезләмә**

1. Әлеге нигезләмә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары нигезендә эшләнгән һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү максатларын һәм шартларын билгели.

2. Комиссиянең максаты – Казан шәһәренең инженерлык сагы гидротехник корылмаларына комплекслы тикшерү уздыру өлешендә Казан шәһәренең гидротехник корылмаларын эксплуатацияләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатыннан оешмаларга Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе (алга таба – Тәртип) һәм әлеге нигезләмә нигезендә вәкаләтле органга килеп ирешкән гаризаларны карап тикшерү.

3. Вәкаләтле орган субсидияләр бирү буенча составы Казан шәһәре Башкарма комитеты карары белән раслана торган комиссия төзи.

4. Комиссия составына комиссия рәисе һәм әгъзалары керергә тиеш. Конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми саны – кимендә өч кеше.

Комиссия рәисе:

- комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итә;
- комиссия утырышларында рәислек итә;
- комиссия эшен оештыра;
- комиссия утырышын уздыру урынын, көнен, вакытын һәм формасын билгели.

Комиссия рәисе яки әгъзасы булмаган очракта, комиссия эшендә аның вазифаларын вакытлыча башкаручы зат катнаша.

Комиссия әгъзалары составына кергән сәркатип:

- комиссия утырышларына материаллар әзерләүне тәэмин итә;

- комиссия утырышын уздыру урыны, көне һәм вакыты турында комиссия әгъзаларына үз вакытында хәбәр итә;

- комиссия утырышлары беркетмәләрен алып бара;

- комиссия документларын саклауны тәэмин итә.

Комиссия әгъзалары:

- комиссия эшендә шәхсән катнашалар, катнаша алмаган очракта, комиссия сәркатибенә бу хакта мөмкин булган ысул белән алдан ук хәбәр итәләр;

- гаризаларны карап тикшерәләр.

5. Комиссия утырышын уздыру көне, вакыты һәм урыны турындагы мәгълүмат комиссия сәркатибе тарафыннан комиссия әгъзаларына комиссия утырышын уздыру көненә кимендә ике эш көне кала хәбәр ителә.

Комиссия эше утырыш формасында алып барыла, ул турыдан-туры катнашып та, видеоконференция режимында да уздырылырга мөмкин.

Комиссия утырышында комиссия составына керүче кимендә өч зат катнашкан очракта, комиссия утырышы тулы хокуклы булып санала.

Комиссия үз утырышларында катнашу өчен экспертлар җәлеп итәргә хокуклы.

6. Комиссия карарлары, ачык тавыш бирү ысулын кулланып, комиссия составына керүче утырышта катнашкан затларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез булганда, конкурс комиссиясе утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып санала.

Сайлап алу җиңүчесен билгеләү комиссиясе карарлары беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә, ул комиссиянең утырышта катнашучы барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.

7. Комиссия:

- сайлап алуны уздыру турындагы белдерүдә билгеләнгән сайлап алуны уздыру вакыты дәвамында гаризаларны, кабул итү көнен һәм вакытын күрсәтеп, алар кергән көнне терки;

- Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан яки Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә соратып алуга мөрәҗәгатьләр юллый (Федераль салым хезмәтенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге https://nalog.ru рәсми сайтыннан бастырып алына);

- сайлап алу үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән сайлап алуны үткәрү вакыты тәмамланган көннән алып ун эш көне эчендә тапшырылган документларны Тәртип белән билгеләнгән, Казан шәһәре Башкарма комитеты карары белән расланган таләпләргә туры килү-килмәү предметына карап

тикшерә һәм сайлап алу җиңүчеләрен билгеләү яки гаризаны кире кагу турында карар кабул итә;

- сайлап алу җиңүчеләрен билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге бердәм порталда һәм рәсми порталда сайлап алу нәтиҗәләре турында түбәндәге белешмәләрне үз эченә алган мәгълүмат урнаштыра: гаризаларны карап тикшерүне уздыру көне, вакыты һәм урыны; гаризалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат; гаризаларны кире кагу сәбәпләрен, шул исәптән мондый гаризаларның сайлап алу уздыру турындагы белдерүнең кайсы нигезләмәләренә туры килмәвен күрсәтеп, гаризалары кире кагылган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат; сайлап алуда җиңүчеләрнең атамалары һәм аларга бирелә торган субсидия күләме.

8. Комиссия субсидия бирү турында яки субсидия бирүне кире кагу турында карарны сайлап алуда катнашучыларның сайлап алу категорияләренә, критерийларына туры килүен һәм гаризаларның керү чиратын исәпкә алып кабул итә.

9. Гаризаларны карап тикшерү стадиясендә аларны кире кагу өчен нигезләр:

- оешманың Тәртиптә күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве;

- тапшырылган гаризаның һәм документларның сайлап алуны уздыру турындагы белдерүдә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

- сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөреслеккә туры килмәве;

- документларның тулы булмаган җыелмасын тапшыру;

- бюджет йөкләмәләре лимиты бетү.

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 13 декабрендәге
5160 номерлы карарына
3 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең инженерлык сагы гидротехник корылмаларына комплекслы тикшерү уздыру өлешендә Казан шәһәренең гидротехник корылмаларын эксплуатацияләүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү максатыннан оешмаларга субсидияләр бирү комиссиясе составы**

Комиссия рәисе – Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитеты рәисе.

Комиссия сәркатибе – Казан шәһәре Башкарма комитеты Торак-коммуналь хуҗалык комитетының суүткәргеч-канализация һәм энергетика хуҗалыгы бүлеге баш белгече.

Комиссия әгъзалары:

- Казан шәһәре Башкарма комитеты Торак-коммуналь хуҗалык комитеты рәисенең суүткәргеч-канализация һәм энергетика хуҗалыгы мәсьәләләре өчен җаваплы урынбасары;
- Казан шәһәре Башкарма комитеты Торак-коммуналь хуҗалык комитетының суүткәргеч-канализация һәм энергетика хуҗалыгы бүлеге башлыгы;
- Казан шәһәре Башкарма комитеты Торак-коммуналь хуҗалык комитетының финанслау, исәп һәм контроль бүлеге башлыгы.

Искәрмә. Комиссия әгъзалары комиссия утырышларында шәхсән катнаша. Комиссия әгъзасы булмаган очракта, комиссия эшендә аның вазифаларын вакытлыча башкаручы зат катнаша.

________________